Рәшид Амишов

# ДИН ГАЛИМЕ НУРГАЛИ ХӘСӘНОВ





*Нургали Хәсәнов эшләгән Буа мәдрәсәсе комплексы уку биналары.*
*Алгы планда 1916-1917 елларда, арттагы - 1850 елларда төзелгән бина. 1997 елгы фото.*



*Буа мәдрәсәсенең 1999-2001 елларда салынган хәзерге төп уку бинасы, 2020 ел*

Р.И. АМИШОВ

# ДИН ГАЛИМЕ НУРГАЛИ ХӘСӘНОВ

ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ



ТАТАР ХАЛКЫНДАГЫ ИСЛАМ ДИНЕ
ҮСЕШЕНӘ ХЕЗМӘТ КУЙГАН
БАРЛЫК КҮРКӘМ ШӘХЕСЛӘР
ХӨРМӘТЕНӘ БАГЫШЛАНА

Казан • 2022

УДК 28-335
ББК 86.38-4-3,8 Хасанов Н.
А62

**Ошбу китапны бастыруда олы рәхмәтебезне белдерәбез Хәсәнҗанов Алмаз Равил улына - табиб, эшмәкәр (Буа шәһәре)**

**Фәнни мөхәррир:**
**Каюмов Рифат Хәсәнҗан улы,** тарихчы, җурналист, җәмәгать эшлеклесе.

**Абзалов Ленар Фиргать улы,** Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты «Тарих фәннәре һәм Бөтендөнья мәдәни мирас югары мәктәбе» бүлегенең төбәк белеме һәм Евразия тикшеренүләре кафедрасы доценты, тарих фәннәре кандидаты.

**Рецензент:**

**Салихов Радик Рим улы**, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры, ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе.

**Шагавиев Дамир Әдһәм улы,** Россия ислам институтының Ислам теологиясе кафедрасы доценты, Болгар ислам академиясенең өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты.

**Текст мөхәррире:**
**Сәлахов Рифат Гали улы,** шагыйрь, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.

**Амишов Р.И.**
А62 Дин галиме Нургали Хәсәнов: тәрҗемәи хәле. — Казан: ПФ «ГАРТ» нәшр., 2022. — 40 б.

Әлеге китап, күп чыганаклар һәм әдәбият нигезендә, Урта Идел буендагы революциягә кадәрге чорында яшәгән танылган дин галиме, ишан, җәмәгать эшлеклесе Нургали Хәсәновның кыскача биографиясенә багышлана. Ул, үзенең күпкырлы тормышы һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән, татар халкы тарихында тирән эз калдырган. Мәшһүр дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең якын фикердәшләреннән саналган һәм эшчәнлеге белән революциягә кадәрге чорда күп абруйлы шәхесләре белән бәйле булган. Нургали Хәсәнов утыз елдан артык Сембер губернасы Буа шәһәре мәдрәсәсен җитәкләгән, ахун, имам вазыйфаларын башкарган, бик күп кешеләргә гыйлем һәм рухи тәрбия биргән. XIX гасыр азагы – XX гасыр башында аның байтак укучылары имам һәм танылган татар җәмәгать һәм дин эшлеклеләре булып халыкка уңышлы хезмәт иткәннәр. Галимгә казанышлары өчен Россия һәм Госманлы империясе хакимияте тарафыннан югары дәүләт бүләкләре бирелгән.

Әлеге китап тарихчылар, укытучылар, студентлар, Ислам һәм татар халкы тарихы белән кызыксынучылар өчен тәкъдим ителә.

УДК 28-335
ББК 86.38-4-3,8 Хасанов Н.

ISBN 978-5-6044795-3-7

© Издательство ПФ «ГАРТ», 2022
© Амишов Р.И., 2022

# КЕРЕШ

Татар халкы талантларга бай – танылган галимнәр, күренекле җитәкчеләр, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, иганәче сәүдәгәрләр илебез, милләтебез үсешенә бәяләп бетергесез өлеш керткәннәр. Гыйлем таратуда, рухи тәрбия бирүдә һәм милли гореф-гадәтләребезне саклап калуда дин галимнәре, ишан һәм имамнарның хезмәтләре гомер-гомергә зур булган. Алар арасында танылган дин эшлеклесе, галим, мәгърифәтче Нургали Хәсән улы Хәсәнов (1852-1919) – Урта Идел буеның XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында яшәгән иң күренекле вәкилләренең берсе. Аның киңкырлы тормышын, иҗади мирасын өйрәнү – милләтебез тарихы, илебездә Ислам динене үсешенә хезмәт куйган күркәм шәхесләрне ачыклау юлындагы мөһим адым.



*Нургали хәзрәт Хәсәнов*

Нургали Хәсәнов хакында үз хезмәтләрендә күренекле шәхесләрдән Ризаэддин Фәхреддин (XIV, б. 328), [1, б. 444], Морад Рәмзи [2, с. 486], Галимҗан Баруди [3, б. 63], Миркасыйм Госманов [4, б. 227], Рамил Хәйретдинов һәм Радик Салихов [5, с. 98; 6, с. 241], Габделхак Саматов [7, б. 152], Александр Кобзев [8, с. 285], Ибраһим Мараш [16, с. 154], Рифат Каюмов [17] һ.б. өлешчә язганнар. Тирәнрәк тарихчы Омар Хакан Озал (Төркия) тарафыннан өйрәнелеп, галимнең ике хезмәте төрек теленә тәрҗемә ителеп басылган [18]. Нургали Хәсәнов тормышы һәм эшчәнлеге турында тулы мәглүмат Ульяновск өлкәсе дәүләт архивында, Татарстан Республикасы Милли архивында, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте-

нең Татарстан Республикасы буенча идарәсе архивында, Башкортостан Республикасының тарихи үзәк дәүләт архивында һәм Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә документлар, язмалар, газеталарда басылган мәкаләләр рәвешендә сакланган. Ул үз тормышы турында «58 ел гасырда җәүәлән» (XII) һәм «Әл-гауатыф әл-хамидия фиссаяхати нурия» («Якты сәяхәтнең игелекле хисләре») (XI) дигән автобиографик әсәрләрдә кыскача язып калдырган.

Югарыда әйтелгән хезмәтләргә, архив чыганакларга, революциягә кадәрге татар матбугатына, замандашларының язмаларына һәм варисларның истәлекләренә нигезләнеп, сезнең игътибарга аның кыскача тормыш юлын һәм эшчәнлеген чагылдырган шушы хезмәтебезне тәкъдим итәбез. Күбрәк мәгълүматны *Амишов Р.И. Татарский богослов Нургали Хасанов. – Казань: Изд-во «Магариф – Вакыт», 2022. – 336 с.* китабыннан укып белә аласыз.

## I БҮЛЕК. УКУ, БЕЛЕМ ТУПЛАУ ЧОРЫ
### 1.1. Балачак һәм уку еллары

Хәсәнов Нургали Хәсән улы 1852 елның 8 ноябрендә Казан губернасының Тәтеш өязе Морзалар авылында (хәзерге Апас районында) затлы дин әһелләре гаиләсендә дөньяга килә. Ул борынгы татар морзалары нәселеннән була. Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә күрсәтелгән: «Идегәй морза (Алтын Урда чоры) → Морадин → Оказ → Муса → Исмәгыйль → Ырыс → Иши → Гали → Ибраһим → Әсән → Мөслим → Дауд → Мөэмин → Исмәгыйль → Хәсән → Нургали» [1, б. 444; 9, б. 24].

Аның әтисе Хәсән хәзрәт Исмәгыйль улы (1820-1882) күренекле дин әһеле, ишан булган һәм 40 ел дәвамында Морзалар авылында мулла булып хезмәт иткән. Әнисе дә Югары Балтай авылыннан затлы морзалар нәселеннән булган. Нургали дөньяга килгәнче үк, әти-әнисе ниндидер җитди сәбәпләр аркасында аерылышканнар. Ул, әтисе йортында туып, әнисе, әби-бабасында тәрбияләнгән. Алты яшендә аны Казандагы әнисенең абыйсы чакыруы белән, Дүртенче җәмигъ мәчетенең (хәзерге Зәңгәр мәчет) мәдрәсәсенә галим, шагыйрь Гаясетдин бине Хәбибуллага (1830–1870) укырга бирәләр. Күп тә үтми, Нургалинең әнисе, кияүгә чыгып, Казанга күчә. Ләкин аңа озак яшәргә насыйп булмый – бакыйлыкка китә. Нургали әнисе ягыннан әби-бабасы тәрбиясендә кала. Алар аның әхлаклы, белемле булуына зур игътибар биргәннәр. Әмма, озак та үтми, бер-бер артлы, дөньядан киткәннәр. Кечкенә Нур-



*Нургали Хәсәновның әтисе –*
*Хәсән хәзрәт кабере.*
*Татарстан Республикасы,*
*Апас районы Морзалар авылы,*
*2020 елгы фото.*



*Зәңгәр мәчет, Казан шәһәре.*
*020 елгы фото*

гали бик кыен хәлдә кала. Мохтаҗлыкка, кыенлыкларга карамастан, ул мәдрәсәдәге укуын тагын да зур тырышлык белән дәвам итә. Уку китапларын һәм аларга аңлатмаларны өйрәнеп кенә калмыйча, ул аларны хәтта ятлап бара. Мәсәлән, шулар арасында ул Ислам хокукы нигезләре буенча «Ән-Нукая мухтасар әл-Викая» («Әл-Викая китабының кыскача аңлатмасы») дигән зур күләмле китап та була (XII, б. 1–2, 6).

Нургали укыган мәдрәсәнең җитәкчесе, яраткан остазы Гаясетдин хәзрәт вафат булгач, аны әнисенең туганы Оренбургка Госман хәзрәт мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр, анда ул Галиәсгар бине Габдуллаһ остазда ике ел укый. Ахырда әтисе ярдәме белән ул укуын Казандагы атаклы һәм борынгы Апанай мәдрәсәсендә дәвам итә (башка исемнәре Күл буе, Касыймия). Шул вакытта мәдрәсәнең җитәкчесе Сәлахеддин бине Исхак (1820–1875) булган (XII, б. 1–2).

Мәдрәсәдә Нургали Хәсәновка ошбу остазлар белем бирә: гакыйдә буенча дамелла Сәлахетдин бине Исхак,  гарәп һәм фарсы телләрен Җәмәд бине Халид укыткан, ысуле-хикмәт буенча дамелла Таҗетдин бине Бәшир (III, оп. 7, д. 909, л. 86 об.), Коръән уку буенча кари Шәмсетдин бине Шәрәфетдин, Мөкаддәм хәлфә Әшнәки һәм Хәйретдин хәл-



*Апанай мәдрәсәсе, мәчете биналары, Казан шәһәре. 2020 ел*

фә, гарәп теле грамматикасы (нәхү) һәм морфологиясе (сарф) буенча Гыймадеддин әл-Бәдәнки, мирас (мизан) буенча Нургали бине Габдеррәкыйб әл-Баруди (1836–1895). Камәлетдин хәзрәттә ул төрле өстәмә дини фәннәр өйрәнгән (XII, б. 6) [1, б. 444]. Курсташлары арасында булачак күренекле дин әһелләре дә укыган: мөфти Галимҗан Баруди, Земницы авылының имамы Җәләлетдин хәзрәт, Гурьевка авылы имамы Сәлахетдин хәзрәт, Стәрлетамак имамы Гариф хәзрәт Бәхтияров һ.б. [1, б. 241].

Нургали хәзрәт укыту эшчәнлеген иртә башлый. Гыйлем алу, күп кенә китаплар өйрәнү белән беррәттән, ул мәдрсәнең яшь шәкертләренә дәресләр бирә. Бу эшчәнлектә аның сәләте ачылып, ул зур уңышларга ирешә һәм ихтирам казана. Укуын тәмамлагач та, Апанай мәдрәсәсендә эшкә кала. Шулай итеп, ул Казанның атаклы хәлфәсе, күренекле яшь мөгаллимнәрнең берсенә әйләнә (XII, б. 6).

## 1.1. Бохарада уку

XIX гасыр ахырына кадәр татарлар арасында Урта Азиянең Бохара, Сәмәрканд, Хива шәһәрләрендәге дини үзәкләрдә белем алу бик дәрәҗәле булып саналган. Анда күп кенә дини уку йортлары, китапханәләр урнашкан булган, күп кенә дин галимнәре яшәгән. Бохарада

гыйлем туплаган дин әһелләре халык арасында зур хөрмәткә ия булганнар, аларны «дамелла» дип йөрткәннәр. Нургали дә әтисе Хәсән хәзрәттән, остазларыннан рөхсәт һәм хәер-догаларын алып, 1876 елны 26 яшендә Бохараның танылган «Мир-Гарәб» мәдрәсәсенә укырга китә. Камал ишан, Хәким мәхдүм, Әгъләм хәзрәт, Садыр казый, мөфти Әбү Насыр, мөфти Борһан, мөфти Габделхәким хәзрәт, Күкелташ ахуны Ихтыяр хәзрәтләрдән ул зур дини гыйлем ала (XII, б. 6) [1, б. 444].



*«Мир-Гарәб» мәдрәсәсе, Бохара шәһәре. 2020 ел*

Җиде ел тырышып укыганнан соң, 1883 елда Нургали шәкерт мәдрәсәне тәмамлый (V, оп. 1, д. 1182, л. 42-42 об.). Бохара голәмасының махсус дини җыелышында имтиханнарны уңышлы тапшырып, гыйльми дәрәҗә ала һәм Бохара галимнәре арасына керә (XII, с. 7). Бохара әмирене Мозаффарның хөрмәтенә, бүләкләренә лаек була. 1883–1885 елларда Нургали хәзрәт Бохараның бер мәдрәсәсендә укыта башлый һәм тагын өстәмә гыйлем алуын дәвам итә. 1885 елны имтиханнарын кабат югары билгеләргә тапшырып, Бохарадагы «Гатар» мәдрәсәсендә җитәкче булып эшли башлый. 1886 елны шул шәһәрдә яшәүче Хәлимә-ай (Хәлиябанат) Габдрахман кызына өйләнә. (IV, оп. 4, д. 264, л. 7, 16).

Нургали хәзрәт үзенең уку дәверендә күп төрле дини фәннәрне, китапларны укытуга иҗазәтләр (рөхсәтләр) ала. Мәсәлән, 1876 елда Казанда Сәлахетдин һәм Таҗетдин бине Бәшир мөдәррисләрдән, Боха-

рада Күкелташ ахуны Ихтыяр хуҗадан, шәех Нуретдин әл-Хәвәрезмидән, Сираҗетдин мөфтидән, шәех Тура Бохариядән, соңрак Сәедгали әл-Витри әл-Мәдинидән (хәдис җыентыклары буенча) һ.б. [1, б. 444].

Туган ягына кайтканнан соң, 1893–1896 елларда Нургали Хәсәнов вакытлыча эшләрен калдырып, үзен тулысынча тарикать юлында суфичылыкны җентекләп өйрәнүгә һәм рухи яктан камилләшүгә багышлый. Янәдән Бохара шәһәренә укырга китә. Анда Миян Мәлик ишан әл-Бохарида, соңрак Әстерхан шәһәрендә Нәҗметдин ишан әл-Әстерхани, Троицкида Зәйнулла ишан Рәсүлевтә (1833-1917) дә мөрид булып озак вакытлар укый, рухи яктан тәрбияләнә. 3 ел эчендә аларның һәрберсендә махсус гыйлемнәр алып һәм югары рухи яктан камилләшеп, нәкъшбандия тарикатындагы ишан дәрәҗәсенә ирешә, суфичылык юнәлеше буенча кешеләрне тәрбияләргә рөхсәтләр ала. Моннан тыш, хаҗ кылганда Нургали Хәсәнов Госманлы хәлифәтендә (Төркия) яшәгән күп кенә күренекле дин әһелләре, ишаннар белән очраша, кайберләреннән хәтта иҗәзә ала. Мәсәлән, Истанбулда шәех Әбүл Һуда әр-Рифаги (1909 елда вафат) аңа рифагый тарикате (суфичылыктагы рухи юнәлешләренең берсе) буенча укучылар тәрбияләргә рөхсәт бирә.



*Шәех Зәйнулла Расули*



*Шәех Әбу әл-Һуда әр-Рифаги*

Шулай итеп, Нургали Хәсәнов шәригать фәннәре һәм тарикать (суфичылык) буенча галим дәрәҗәсенә ирешә (XII, б. 6–10), [1, б. 445; 7, б. 152].

# II БҮЛЕК. БУА ТӨБӘГЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ.
## 2.1. Имам һәм мәдрәсә җитәкчесе




*Габденнасыр хәзрәт сүрәте[1] һәм аның Буа шәһәрендәге кабере*

1886 елда Нургали Хәсәновның Бохарадан кире туган ягына кайтуының сәбәбе – танылган дин эшлеклесе, галим, Буа мәдрәсәсе җитәкчесе һәм Буа шәһәре җәмигъ мәчете имамы Габденнасыйр Мөхәммәдәминовның үлеме (1806–1886) була. Аны җирләгәннән соң, Буа байлары шундый ук гыйлем иясе булган җитәкчене эзли башлыйлар. Бу мөһим эш белән II гильдия сәүдәгәре, танылган хәйрияче Шәриф (Мөхәмматшәриф) Муллин (1821–1905) шөгельләнә. Аның чакыруы буенча, Нургали Хәсәнов, тәвәккәлләп гаиләсе белән 34 яшендә Буа шәһәренә әйләнеп кайта. Халык шатланып аны бертавыштан имам һәм мәдрәсә җитәкчесе итеп, җаваплы вазыйфага сайлый. 1886 елның 12 декабрьнда рәсми документлар алып ул шул җирлектә 30 елдан артык гомерен әлеге хезмәткә багышлый (III, оп. 7, д. 909, л. 121; XII, б. 23–24).

Буа – борынгы заманнардан билгеле, зур булмаган өяз шәһәре була. Ул Казаннан 137 км, Сембер (Ульяновск) шәһәреннән 80 км ераклыкта урнашкан. Бирәдә дәүләт оешмалары, вак сәнәгать йортлары (күн, кирпеч, туку һ.б.), сәүдә, уку йортлары, өяз хастаханәсе, төрмә, гыйбадәтханәләр булган. Күпчелек биналар бер катлы булган. Агачтан тө-

[1] Тарихи реконструкция. Картина авторы – Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге әгъзасы Бакиров Илнур Мансур улы. 2020 ел.

зелгәнгә күрә, төрле сәбәпле шәһәр күп тапкыр янган (1551, ... 1704, 1882, 1897 елларда), әмма яңадан төзелгән һәм торгызылган. 1871 елда Буада 4127 кеше яшәгән, аларның 1500-се татар, калганнары урыс һәм чуашлар булган. Татар халкы шәһәрнең татар бистәсендә, үз милли, дини гореф-гадәтләрен саклап, рус мәдәнияте йогынтысыннан читтә, аерым яшәгән. Араларында бай сәүдәгәрләр дә булган, алар өяздә мәчет-мәдрәсәләр төзергә һәм тәэмин итәргә ярдәм иткәннәр.




*Буа шәһәренең топографик планы. 1861 ел. ТР МА, ф.408, оп. 4, д. 226*

Нургали хәзрәт Хәсәнов үзенең киңкырлы эшчәнлеге дәвамында шактый күп эшләр башкара. Мәчет имамы буларак, җәмәгать намазларын җитәкли, гыйлем бирә, суфыйчылык юлында мөридләр тәрбияли, Ислам динен тарату өчен зур тырышлык куя – авыру кешеләрне догалар укып өшкерә, халык чакыруы буенча өйләрдә никах, исем кушу, мәрхүмнәрне озату кебек төрле дини йолаларны үти. Метрика китапларында мәхәлләдә яшәүчеләрнең гражданлык актларын теркәп бара, туу, үлү, гаилә хәле хакында белешмәләр бирә, бәхәсле мәсьәләләрне чишә, мирас малын дин буенча бүлүдә ярдәм итә, төшләр юрый. Ул чорның законнары буенча дин әһеле буларак, ул вазифа алган затлардан, судта гаепләнүчеләрдән, шаһитлардан Коръәнгә кул куйдырып антлар ала, хәрби хезмәткә солдатларны озата. Мәхәллә кешеләре аңа үзләрен борчыган сораулар буенча мөрәҗәгать иткәннәр, аның белән киңәшләшкәннәр, хәер-фатихасын, догаларын алырга тырышканнар (IX, л. 29, VIII, л. 29), [10, с. 6].

Уңышлы хезмәте өчен Нургали хәзрәт 1902 елны Буа шәһәре ахуны итеп билгеләнә. Ул Буа өязендә югары дин әһеле һәм Оренбург мөселманнары Диния нәзарәтенең (алга таба ОМДН) җирле вәкиле буларак,

дәүләт белән җирле мөселманнар арасында арадашчы ролен башкара, мөһим дини чараларны оештыра, төрле мәхәлләләргә дини эшләр буенча йөри, халык арасында җәмәгать җыелышларында дини, иҗтимагый мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый, мәхкәмәләрдә (судларда) эксперт-белгеч буларак катнашу, низагларны чишү кебек төрле вазыйфаларны үти (II, оп. 22, д. 82, л. 1–1 об.; оп. 96, д. 59, л. 19).



*Нургали Хәсәнов эшләгән Буа шәһәренең беренче җәмигъ мәчете. Ул 1882 елны салынган, 1999 елы сүтелеп Буа мәдрәсәсенең мәчете һәм уку бинасы буларак яңадан төзелә. 1990 елгы фото*



*1850 нче елларда салынган Буа мәдрәсәсенең иң борынгы бинасы. Бүгенге көндә бу бина бик авыр хәлдә, төзекләндерелүгә мохтаҗ. 2009 елгы фото*

Нургали Хәсәнов иң күп вакытын Буа мәдрәсәсе шәкертләрен укыту һәм тәрбияләү эшенә багышлый. Өлкән сыйныфларда ул тәфсир, фикъһе, хәдис һәм башка фәннәрдән дәресләр алып бара. Аның тырышлыгы һәм максатчанлыгы нәтиҗәсендә, Буа мәдрәсәсенең элеккеге даны сакланып кала һәм ул чорда Урта Идел буеның алдынгы мөселман уку йортларының берсе булып санала. Мәдрәсәдә Буа өязендә булачак дин әһелләренең күпчелеге укыган. Анда Казан, Сембер, Әстерхан, Саратов губерналарыннан килгән шәкертләр шактый була. 1905 елда мәдрәсәдә 500 гә якын шәкерт белем алган (VI, с. 241); [6, с. 241]. Укучыларның күплеге «укыту программасының киң булуы, шулай ук мөселман халкы үзәгендә урнашкан мәдрәсәнең борынгы даны» белән дә аңлатылган (V, оп. 1, д. 1182, л. 42). 1911 елга кадәр укыту классик дини китаплар нигезендә кадимичә алып барылган (IV, Оп. 1. д. 1930, л. 103; V, оп. 1, д. 1182, л. 42). 1913 елда мәдрәсәдә 12 укытучы эшләгән (I). Мәдрәсә комплексы беренче җәмигъ мәчете ишек алдындагы 2 таш һәм 3 агачтан төзелгән иркен биналарга, хуҗалык корылмаларына урнашкан була.

*Буа мәдрәсәсе шәкертләре фотосурәтләре*



*Сулда – булачак гарәп теле белгече, галим Бакый Халидов*



*Сулда – булачак язучы Шакир Мөхәммәдов*





*Шәкертләр дәрестә*

Нургали Хәсәнов үз гомерендә бик күп шәкертләр укыта һәм тәрбияли. Алар арсында 200гә якыны имам, 10 ахун, 8 зур мәдрәсә җитәкчесе һәм бик күпсанлы мөәззин, укытучылар Идел буеның төрле мәчет

мәхәлләләрендә хезмәт иткәннәр. Укучылары арасында татар халкының абруйлы шәхесләре дә бар. Мәсәлән: тарихчы, күренекле җәмәгать, дин эшлеклесе, II чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты **Һади Атласи** (1876–1938); күренекле дин эшлеклесе, II чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты **Габдулла Нәҗметдинов** (1869–1915); язучы **Зариф Бәшири** (1888–1962); дин галиме, шагыйрь **Мөхәммәд-Садыйк Иманколый** (1870-1932); күренекле дин эшлеклесе **Камәртдин Салихов** (1890–1962); язучы **Гомәр Толымбай** (Г. Ш. Шаһиәхмәтов) (1900–1938); педагог, тәрҗемәче, тел белгече **Бакый Халидов** (1905–1968); журналист, күренекле җәмәгать, дин эшлеклесе **Фатих (Мөхәммәдфатих) Мортазин** (1875–1937); педагог, журналист, нәшир **Шиһабетдин Әхмәров** (1882–1966); тюрколог, журналист, җәмәгать эшлеклесе **Кәрим Сәгыйди** (1888–1939); прозаик, драматург **Ярулла Вәли** (1879–1937); танылган җәмәгать эшлеклесе, педагог, публицист **Ибраһим Бикколов** (1884-1938); күренекле педагог **Фатих Садыйков** (Капал Садики, Фатих Капал); мәшһүр каллиграф **Гарифҗан Вәлиди** (Гарифҗан Буави, 1879–1946); Самара шәһәре ахуны, Самараның 1нче җәмигъ мәчете, мәдрәсәсе җитәкчесе **Шиһабетдин Минюшев** (1855–1930); күренекле дин эшлеклесе, Буа өязе ахуны **Габделсамад Шәһидуллин** (1866–1928), журналист, язучы **Рәуф (Габдрәуф) Шәһидуллин** (1889?-1942); партия, идарә хезмәткәре **Нури Алиев** (1898-1961), Миасс шәһәрендәге танылган дин әһле, нәшир **Саләхктдин Бәширов** (1862–193?), танылган дин әһле, Касыйм, соңрак Петрограда ахуны **Фаттәхетдин Давлеткамов** (Давлекамов) (1875–193?) һәм башкалар [10, с. 4].

## Нургали Хәсәннең шәкертләре



*Һади Атласи*



*Габдулла Нәҗметдинов*



*Шакир Мөхәммәдов*



*Камәретдин Салихов*



*Фатих Әхмәров*



*Гөмәр Толымбай*



*Гарифҗан Вәлидов*



*Фатих Мортазин*



*Зариф Бәшири*



*Бакый Халидов*



*Ярулла Вәлиев*



*Нури Алеев*



*Шиһабетдин Минюшев*



*Ибраһим Бикколов*



*Гбдульсамад Шаһидуллин*



*Мөхәммад-Садыйк Иманкулов*



*Саләхетдин Бәширов*

## 2.2. Иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге

Дин галиме Нургали Хәсәнов татар милләтенең, мөселман өммәтенең хәлен күреп, аларның проблемаларыннан читтә кала алмаган. Мөмкинлеге булган кадәр, ул үз халкын яклап чыгып иҗтимагый тормышта актив катнашкан. Мәсәлән, 1905 елның 17 мартында, Буа өязе ахуны Габделсамад Шәһидуллин белән бергә, үз мәчетендә Буа өязенең һәр мәхәллә мулласын һәм икешәр вәкил чакырып – 250 кеше җыеп, корылтай уздырган. Катнашучылар Россия императоры исеменә төрле сәяси таләпләр һәм үтенечләр кергән петиция төзегәннәр: «Барча мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм вакыфлар ОМДН (мөфтият) карамагында булуы; керәшен татарларына христиан диненнән ирекле рәвештә исламга күчүне закон белән рөхсәт итү; мөселманнар тәрбияләгән

ташланган балалар закон буенча мөселман була алулары; мөселман руханиларының хокукларын православие руханилары белән тигезләү; муллалар өчен рус телен мәҗбүри рәвештә уку чикләүләрен бетерү; татарларга газета, журналларны бастырырга рөхсәт бирү; татарларга дәүләт хезмәтенә эшкә керә алу; татар телендә профессиональ уку йортларын ача алу…» һ.б. язганнар. Шуңа охшаган язмалар башка татарлар яшәгән төбәкләрдән дә язылып дәүләткә җиткерелгән. Шул елны революция булу нәтиҗәсендә, император Николай II хөкүмәте югарыда әйтелгәннәрнең кайберләрен гамәлгә кертергә мәҗбүр булган (III, оп. 2, д. 1446, л. 6–9).

XX гасыр башында Россия империясенең хакимият даирәләре вәкилләре, депутатлар, сәясәтчеләр арасында даими рәвештә шовинистик һәм ксенофоб идеяләр алга чыккалаган. Дәүләт Думасының кайбер фракцияләре яки аерым депутатлары прогрессив мөселман дин әһелләренә каршы репрессияләр, мәктәп-мәдрәсәләрнең эшчәнлеген кысу, җомга көннәрендә һәм дини бәйрәмнәр вакытында мөселманнарга ял итүне, туган телдә белем бирүне тыю кебек һ.б. чыгыш ясаганнар. Аларга каршы татар җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре даими һәм массакүләм рәвештә протест компанияләрен оештырганнар. Дин



*Нургали Хәсәнов, XX гасыр башы*






*Мөһердәге язуның тәрҗемәсе: «Аллаһның рәхмәтенә мохтаҗ булган Аның колы Нургали мулла Хәсән улы»*

*Галимнең мөһерләре һәм имзасы*

галиме Нургали Хәсәнов мондый чараларда еш катнашкан. Мәсәлән, 1910 елда 11 июнь кичендә ул һәм ахун Габделсамад Шәһидуллин Норлат авылы имамы Мирзаәкрам ишан Мостаев (1863–1930) янына килгәннәр. Анда Иске Тинчәле авылы мулласы Гариф Әхтәпов, волость старшинасы Гыйниятулла Хисмәтуллин, Иске Суыксу авылы мулласы Габделвахит Шәрәфетдинов булганнар. Алар бергә, Буа өязе мөселманнарының үз дини бәйрәмнәрендә ял итү һәм милли мәгариф системасын татар телендә, үзгәрешсез итеп саклап калырга теләве хакында, хөкүмәткә ни рәвешле итеп белгертергә икәнлеге турында фикер алышканнар. Нәтиҗәдә, имамнар һәм мәхәллә кешеләре арасында тиз һәм бердәм эш корып, 1910 елның көзенә үк алар Тәтеш һәм Буа өязләренең барлык татар авылларыннан Дәүләт Думасы депутатларына күмәк үтенечләр һәм таләпләр җибәргәннәр. Мәсәлән, Иске Суыксу, Иске Тинчәле, Норлат, Түбән Наратбаш авыллары халкының рәсми хатларында «татар мәктәпләрендә укулар шулай ук искечә – элеккеге китаплар һәм әлифбалар буенча башкарылсын, мөселманнар өчен ял көне итеп җомга көне калдырылсын», – диелгән була. Бу чараларда Урта Иделнең татарлар яшәгән башка өязләре дә катнашкан. Мондый массакүләм акцияләр җирле һәм үзәк хакимият органнарын бик борчуга салган. Нәтиҗәдә сәясәтчеләрнең татар мөселманнарына карата булган гаделсез закон чыгарулардан, шовинистик һөҗүмнәрендә кире кайтырга зур сәбәп булган [5, с. 98; 6, с. 241].

XX гасыр башына кадәр татарларда **җомга хөтбәләре** гыйбадәт өлеше дип, гарәп телендә генә сөйләнгән. Аны үзгәртү, халыкка аңлаешлы итү мәсьәләсе дин галимнәре тарафыннан күтәрелеп чыгыла һәм кайбер бәхәсләргә китерә. 1906 елны Нургали Хәсәнов, Галимҗан Баруди, Габдулла Буби белән беррәттән, иң беренчеләрдән булып аны тиешле рәвештә дәлилләп чыгалар һәм татар телендә үткәрә башлыйлар. Башка дин әһелләре дә моңа кушылып, халыкка җомга вәгазенең төп өлешен ана телендә сөйләүне кулланышка кертәләр (XXIV).

Нургали Хәсәнов шул заманның муллалары кебек үк татар милләтен, аның телен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү өчен күп хезмәт куя. Россия үзәгендә яшәгән татар халкының язмыш халәтен исәпкә алып, татарларның массакүләм **рус телен** өйрәнүенә каршы була. Ул, татарларның урыслар белән якынлашып, аларның мәдәни мохите тәэсирендә үзгәреп, аермалык бетү нәтиҗәсендә урыслашырга мөмкин, дип борчылган. Шуңа күрә Буа мәдрәсәсендә озак вакыт урыс теле укытылмаган. Илдә икътисади, иҗтимагый вазгыять үзгәрү сәбәпле, рус теленең мөһимлеге аңлашыла башлагач, дини гыйлемнәрне, туган

телне укытуны саклаган шартта ул 1911 елдан мәдрәсә программасын замана таләпләренә туры килгән рәвештә үзгәртә һәм булачак имамнарга кирәкле булган гомуми фәннәрне, 1913-14 елдан рус телен укытуны кертә (V, оп. 1, д. 1182, л. 42 об.).

Нургали хәзрәт Хәсәнов, шул чорның татар дин әһелләренә хас булганча, консерватив фикерле һәм традицион карашлы галимнәрдән була. Ул җирле дәүләт хакимияте белән яхшы мөнәсәбәт корып, җирле мөселманнарның җитди мәсьәләләрен чишүдә дәүләт вәкилләре белән уңышлы эш алып бара (III, оп. 2, д. 1446, л. 3). Сәяси яктан ул ватанпәрвәр, дин, милләт үсешенә фидакарь хезмәттә булып, революцион карашларны һәм фетнәләрне кабул итмәгән. Ул патшага һәм дәүләтнең иминлеге өчен һәрдаим дога кылган. Хакимият вәкилләре дин әһеленең халык арасында булган югары абруен, йогынтысын исәпкә алып, аңа зур хөрмәт белән караганнар. Татар имамнары арасында ул патшадан иң күп орден-медаль алучылардан саналган. Моның өчен татар халкының мәшһүр шагыйре Габдулла Тукай һәм язучысы танылган Фатих Әмирхан тарафыннан тәнкыйтькә дучар ителгән (13, б. 72; XXIII). Нургали Хәсәнов хакимият белән ышанычлы мөнәсәбәттә булуына карамастан, дини һәм милли мәнфәгатьләр белән бәйле принципларыннан тайпылмаган. Ул аларны төбәк дәрәҗәсендә хикмәт белән яклап килгән һәм галим буларак үз сүзен әйткән (XV; III, оп. 2, д. 1446, л. 6–9).

Нургали Хәсәнов Буа шәһәрендә һәм өязендә яшәүче **православие тарафдарларына** хөрмәт белән караган (VI, л. 60–60 об.). Актив рәвештә керәшен татарлары һәм чуашлар арасында Ислам динен тарату өчен тырыша. Мәдрәсәсендә Исламны кабул иткән чуаш гаиләләренең күп кенә балаларын укыта. 1905 елны илдә дин ирege законы кертелгәч, ул Буа тирәсендә яшәүче мөселман диненә күчкәннәрне үз мәхәлләсенә терки (IV, оп. 1, д. 1930, л. 109). 1901 елны Касыйм шәһәренең танылган православ миссионеры Доронкин В.В. татарларга мөрәҗәгать итеп махсус брошюра бастыра. Анда ул Исламда кимчелекләр эзләп, православия динен хак дин дип күрсәтергә тырыша шуңа ияррергә чакыра. Нургали хәзрәт иң беренчеләрдән булып миссионерның фикерләре хаталы икәнен дәлилләп, аңа каршы зур мәкалә язып җибәрә [2]. Гомумән, ул үз чорының татар дин әһелләре арасында Ислам диненә уңышлы дәгъватт алып барган күренекле шәхесләрнең берсе була (10, б. 42-43).

XIX ахыры – XX гасыр башында татар халкы арасында **җәдитчелек** (яңа заманга яраклашу) фикерләре таралган. Электән килгән кадим-



*Нургали Хасановның йөзеге рәсеме «Мулла Нургали мударрис» дип язылган*

чә (консерватив, искечә) яшәү тарафдарлары белән алар арасында зур бәхәсләр туган. Нургали Хәсәнов бу фикри мәсьәләдә урталык юлын сайлаган. Җәдитчелекнең файдасын ул сәүдә эшен алып баруда һәм төрле фәннәрне өйрәнүдә күргән. Әмма, борынгы китапларны өйрәнүгә, дискуссияләр һ.б. алымнар аша гыйлем алуга нигезләнгән кадимчелекне, Бохара укыту методикасын, ул иң яхшысы дип санаган (XII, б. 29). 1906 елның августында Санкт-Петербургка сәфәр кылганда, Габдеррәшит Ибраһимов, Муса Бигиев, Гатаулла Баязитов һ.б. кебек күренекле татар дин һәм җәмәгать эшлеклеләре алдында түбәндәге сүзләр белән чыгыш ясаган: «Кадимчелекне – иске нигезләрне сүгү – артык кирәкмәгән бер эштер, чөнки аның ярдәмендә без һәм безгә кадәр яшәгәннәр белем һәм мәгърифәткә ирешкәннәр. Яңа юлны – җәдитчелекне дә сүгү, шулай ук, кирәкмәгән артык эштер, чөнки вакыт үзгәрү сәбәпле, безнең тормышка яңалыклар да керә... Алар икесе дә – ике юл, ул юллар башка юлларның булуын инкяр итмиләр, дияргә кирәк. Бер юл – бер төркем өчен, ә икенче юл – икенче төркем өчен. Берсесе [ысуле кадим] укыту өчен туры килә, икенчесе [ысуле җәдит] яңаны башлау өчен туры килә. Дөрес сайларга кирәк – хикмәт белән уртача булуны. Чамасызлыкны һәм ваемсызлыкны калдырырга кирәк» (XI, с. 11). 1906 елдан ул Буа мәдрәсәсендә элеккеге укыту тәртибен әкренләп үзгәртә башлый, ә 1911 елдан, кадими тәртипләрне конфессиональ юнәлешен саклаган нигездә, тулысынча җәдитчә укыту формасын кертә (XVI).

Галим Нургали Хәсәнов үз заманында хәлле кешеләрдән санала. Үзенең маллыннан ул **хәйриячелек** юлына өлеш чыгарырга юмарт булган. Даими рәвештә мохтаҗ укучыларга ярдәм иткән, китаплар бастырган һәм аларны тараткан. Үз мәдрәсәсендә ул күп кенә ятим, мохтаҗ укучыларны сыендырган. Үзенең вәгазьләрендә халыкны хәйриячелек эшенә, авыр хәлдә калганнарга ярдәм итүгә өндәгән. Буа мәдрәсәсен тоту өчен иганәчеләр җәлеп итү өчен тырышкан. Алар ярдәмендә иске биналар ремонтланган, яңалары төзелгән

һәм уку йортының тулы эшчәнлеге тәэмин ителгән. Ул заманда татар сәүдәгәрләре, эшмәкәрләре арасында ихлас юмарт шәхесләр күп булган. Мәсәлән Буа мәдрәсәсен озак еллар Шәриф бай Муллин тәэмин итеп торган. 1905 елны ул вафат булгач Нургали Хәсәнов үз мәхәлләсендәге хәлле, актив кешеләрдән попечительләр советы оештыра (IV, оп. 4, д. 209, л. 275). Алар мәчет, мәдрәсәнең хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итә, вакыф малларын дөрес кулланышын карый. Галим Казан, Сембер шәһәрендәге сәүдәгәрләр белән дә элемемтәдә тора. Мәсәлән, 1914 елның язында Казанның танылган эшмәкәре Садык (Мухаммедсадык) Галикеев (1847-1919) Буа мәдрәсәсе укытучыларына хезмәт хакы өчен 200 сум бүлеп бирә (XXVI), 1916-1917 елларда Сембер шәһәренең фабриканты Сираҗетдин Бахтеев кирпечтән яңа уку бинасын төзи (XXVII). 1905 елгы революциядән соңгы илдә милли, дини сәясәт яхшырганнан соң Нургали Хәсәнов 1906, 1912, 1914-1917 елларда җирле хакимияттән (Буа өзе управасыннан) мәдрәсә эшчәнлегенә матди ярдәмнәр алуга ирешә (XXV, XXVIII, XXIX).



На основании Высочайше утвержденныхъ 4-го Марта 1906 г. Временныхъ правилъ объ обществахъ и союзахъ и согласно журнальному постановленію Симбирскаго Губернскаго по дѣламъ объ обществахъ Присутствія, состоявшагося 16 февраля 1909 г. Мусульманское благотворительное общество въ г. Буинскѣ внесено въ реестръ обществъ и союзовъ по Симбирской губерніи. Февраля 20 дня 1909 года.

За Симбирскаго Губернатора,
Вице-Губернаторъ *Шиловскій.*

Завѣдующій дѣлопроизводствомъ Присутствія
*А. Вознесенскій.*

УСТАВЪ
Мусульманскаго Благотворительнаго Общества
въ городѣ БУИНСКѢ.

I. Цѣль Общества.

§ 1.

Мусульманское благотворительное общество имѣетъ цѣлью вспомоществованіе и призрѣніе бѣднѣйшихъ изъ мусульманъ какъ въ существующихъ богадѣльняхъ, такъ и находящихся въ лечебницахъ и въ другихъ благотворительныхъ учрежденіяхъ, а также содѣйствовать бѣднѣйшимъ ученикамъ мусульманамъ къ поступленію или довершенію образованія, въ низшихъ среднихъ и высшихъ учебныхъ заведеніяхъ, а также въ татарскихъ и проч. школахъ.



ПРОВЕРЕНО 2006 г.

بوا او يازى مسلمانلرى
جمعيت خيريه‌سينڭ
آتچوتى
١٩١٠-١١نچى سنه ايچون.

A. T. S. S. R.-T. M. X. K.
MƏRKƏZ ... həm
PUBLIKA ... XANƏSE.
Научная ... Публичная
БИБЛИОТЕКА
Инв. № 44706
г. ... -Qazan.

КАЗАНЬ.
Электро-типографія „УМИДЪ".
1912.

*Буа өязе мөселманнары хәйрия җәмгыятенең уставы һәм 1911-12 елгы отчеты беренче битләре*

Ул 1910 елда Буа өязе ахуны Габделсамад Шаһидуллин белән «Буа өязе мөселманнары хәйрия җәмгыяте»н оештырган. Анда катнашкан 75 әгъзаның 55-е имам булган. Алар, җыелган акчалардан һәм байларның ярдәм иткән малларыннан, өяздә яшәгән мохтаҗ мөселманнарга ярдәм итү белән актив шөгыльләнгәннәр (XVII, б. 4; XVIII).

Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач та, Нургали Хәсәнов дәүләткә дә хәйрия ярдәме күрсәткән. 1914 елда, Буа өязе муллалары белән, өяз казнасына саллы гына акчалар җыеп биргән (XIX). Яралаган солдатларны дәвалаган Буа земство хастаханәсенә дә ул халыктан җыелган матди ярдәмнәрне, сөлгеләрне, мендәрләрне, кием-салымнарны һ.б. кирәк-яракларны алып килә торган булган (XIX). Диния нәзарәтенең «Мәгълүмат» журналындагы 1917 елгы гыйнвар санында: Нургали Хәсәнов акча җыю оештырып, үз мәхәлләсе исеменнән солдат гаиләләренә 22 сум акча тапшырды, дип язылган (XX). Шулай ук, Нургали хәзрәтнең Истанбулда, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә булганда җирле мохтаҗларга ярдәм итү турында мәгълүматлар сакланып калган (XI, с. 43, 54, 77, 82).

Нургали Хәсәновка үз гомерендә бик күп **сынаулар** аша үтәргә туры килә. Ике улы – Гаяседдин, Ибраһимнан кала, аның төрле яшьтәге күпсанлы балалары вафат була. 1913 елның октябрендә икенче хатыны Бибихаҗәр дә вакытсыз дөньядан китә. Халык арасында зур дәрәҗәгә ия булганлыктан, аңардан көнләшүчеләр һәм аны дошман күрүчеләре дә була. Мәсәлән, Буада татарлар саны күбәеп, 1901 елны икенче мәчетне ачу өчен йөрүчеләргә, «җирле керәшен татарларына начар йогынты ясар» дип, урыс православия чиркәве идарәсе аеруча каршы төшә. Нургали хәзрәттән көнләшүче, дошман күрүчеләр, бу эштә – ул гаепле, малга кызыгып, «яңа мәхәлләне ачуга, мәчетне төзетергә юл куймый», дип, фетнә чыгаралар, төрле нәхак гаепләүләр тараталар, дәрәҗәсен төшерергә тырышалар. 1905 елны губернаторның рөхсәте белән, ниһаять, мәчет төзелеп эшли башлый. Әмма көнчеләр тынычланмыйлар. Алар әледә-әле, аны сәяси яктан ышанычсыз булуда, башка ил файдасына шпионажда, хезмәт вазифаларын үтәмәүдә һ.б. гаепләп, эшеннән азат итүне һәм җаваплылыкка тартуны таләп итеп, мөфти, губерна хакимияте органнары, хәтта патша Николай II исеменә шикаять, әләк язып торганнар. Болар арасында күршесендә яшәгән ике явыз карт булган. Алар озак еллар аның тормышын һәрдаим сөйләп, халыкка уйдырма сүзләр тарата торган булган. Нәтиҗәдә, барлык күпсанлы тикшерүләр, полиция

тарафыннан тентүләр аның гаепсез булуын күрсәтә һәм тагын да дәрәҗәсе артуга китерә. Ахыр чиктә, җирле дәүләт оешмалары 1913 елдан аның өстеннән язган доносларның нигезсез булуын аңлап, игътибар бирми башлаганнар. Бу бөтен уңайсызлыкларны Нургали хәзрәт Аллаһның рәхмәте, сынавы буларак кабул итеп, сабырлык кылып, үз эшләрен уңышлы дәвам иткән. Истәлекләрнең берсендә, ул болай дип яза: «Алар [көнләшкән кешеләр] никадәр безгә карата акылсыз һәм ваемсыз эшләр кылсалар да, бер сүз белән аларга каршы язмадык һәм җавап бирмәдек». «Йөрәгебезне явыз итмәгән һәм аларга каршы тавыш күтәртмәгән Аллага мактаулар булсын! Без начар нәрсәләрне сүз белән дә, язу белән дә таратмыйбыз», дигән (VII, л. 8 об; XI, с. 48).

## 2.3. Хаҗ сәфәре

1906 елның җәендә галим Нургали Хәсәнов хаҗ сәфәренә чыгып китә. Аның бу дәвамлы сәфәре ул чорның күренекле дин галимнәре, суфи ишаннары, сәясәтчеләр белән очрашуларга, аралашуларга бай була. Мәскәү, Петербург, Бакчасарай, Одесса, Истанбул, Бурса, Родос, Дәмәшкъ, Бәйрут, Мәдинә, Мәккә, Җиддә һ.б. шәһәрләрдә булып, күп тарихи урыннарны күрә, гыйбәдәтләр кыла. Истанбулда ул Госманлы империясе җитәкчесе, мөселманнарның танылган хәлифе, солтан Габделхәмид II белән очрашуга лаек була. Алар арасында бик җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Хәлиф аңа зур галим, мөхтәрәм кунак буларак, иң югары хөрмәтен күрсәтә. Аның чакыруы буенча, Нургали хәзрәт Рамазан аен, солтан сараенда үткәрә. Аңа борынгы заманнардан сакланган пәйгамбәрләрнең шәхси әйберләрен, тарихи урыннарны, мөһим уку йортларын, китапханәләрен күрсәтәләр. Моның өстенә, солтан аңа Ислам дине үсешенә зур хезмәте өчен иң югары дәрәҗәдәге дәүләт ордены бирә һәм хөкүмәт делегациясе составында олы хаҗ сәфәре белән бүләкли. Мәдинәдә аны, солтанның мөхтәрәм кунагы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең, Әбү Бәкер һәм Гомәрнең күмелгән урынга (төрбәгә), ә Мәккәдә – изге Кәгъбә эченә кертәләр. Бу сәфәреннән Нургали хәзрәт бик күп гыйбрәт, файда алып кайта һәм күргәннәрен сәяхәтнамә буларак, 1907 елны китап итеп бастыра (XI, с. 75–78; XII, б. 20).





*Мәккәдәге Кәгъбә һәм Мәдинәдәге Мөхәммәд пәйгамбәр мәчете. XX гасыр башы*

# III БҮЛЕК. НУРГАЛИ ХӘСӘНОВ ХАКЫНДА
## 3.1. Галим хакында күренекле шәхесләрнең әйткән сүзләре



Нургали хәзрәт Буа өязенең Күл Черкене авылы имамы Идрис Урманче – танылган татар рәссамы һәм сынчы **Бакый Урманче** (1897–1990) әтисе – белән якын дуслар булганнар. Бакый Урманченың хәтирәләре сакланып калган. Ул анда болай дигән: "Нургали дамелла Буа мәдрәсәсе җитәкчесе булганда, мин кечкенә идем. Аны үзсүзле кеше дип санаганнар, әмма ул бик зур белемгә ия булган. Галимнең сәләте төрле юллар белән аның укучыларына да күчеп барган. Минем танышларым, [татар] интеллигенция арасында, Буа мәдрәсәсен тәмамлаучылар бар: Һади Атласи, Шакир Мөхәммәдов, Капал Фатыйх, Шиһаб Әхмәров, Нури Галиев, Ибраһим Бикколов, Самад ахун Шәһидуллин. Алар барысы да Нургали дамелла укучылары" (XXI).

Халык мәгарифе инспекторы **Н.Самосатский** 1903 елның 25 маенда Нургали Хәсәнов турында үзенең хисабында болай дип яза: «Буа мәдрәсәсендә укырга теләүчеләрнең күп булуы, бу конфессиональ мәктәпнең башлыгы, Буа җәмигъ мәчетенең ахуны Бохара шәһәрендә, андагы «Мир Гарәб» дип аталган югары мөселман дини уку йортында Исламны өйрәнгән, гыйльми дәрәҗәләргә ия булган, урысча белми торган (минем белән тәрҗемәче аркылы сөйләште), дини яктан бик фанат булган, ләкин моның өчен татарлар арасында аеруча хөрмәткә ия булган Нургали Хәсәновның шәхесенә бәйле» (V).



Танылган татар-башкорт шагыйре **Мифтахетдин Акмулла** Нургали Хәсәновкә багышлап тәнкыйди шигырьләр язган. Моның сәбәбе – 1886-1887 елларда эшчәнлегенең башлангыч чорында – галим Шиһабетдин Мәрҗанинең кайбер фикерләрен тәнкыйтьләү була. Акмулла үзенең "Күп сәлам, Нургали мулла, сезгә" дигән шигырендә күренекле галимнең намусын яклап чыга һәм Нургали Хәсәновның Мәрҗани адресына әйтелгән тәнкыйть сүзләрен ачыктан-ачык гаеп итә (4, б. 227).



Татарның мәшһүр дин әһеле, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, мөфти, шәех **Галимҗан Баруди** (1857-1921) Нургали Хәсәнов белән якыннан аралашкан. Үзенең көндәлегендә аңа, галим буларак, уңай бәя бирә, аның мөлаемлыгы турында сөйли. Әмма үз укучысына, Буа шәһәренең 2 нче мәчете имамы, Абдулла Гобәйдуллинга (1923 елда вафат), укыту методларында җәдидчелек юнәлешенә алып барганга, күрәмсен, кайбер басым ясау турында искә ала. Абдулла хәзрәтнең, «…халык арасында ихтирамы һәм дәрәҗәсе үсә, ә киләчәктә ул Нургали хәзрәтне алыштырачак», дип яза (3, б. 63).



Танылган татар дин галиме, мөфти **Ризаэддин Фәхреддин** (1859–1936) Нургали Хәсәнов турында зур галим, ачык һәм мөлаем кеше, дип искәртә. "Бер тапкыр Оренбургта яшәгән вакытта, аның Оренбургка килүе турында белдем. Озак вакыт ул миндә кунак булды", – ди. Мәшһүр галим, суфи Ибн Гарәбига багышланган китабында Нургали хәзрәтнең хаҗ сәфәре вакытында аны күргән рәсем тасвирламасын китерә (XIV б. 328; 1, б. 667).



Күренекле татар дин галиме, тарихчы, шәех **Морад Рәмзи** (1854–1934) 1908 елда үзенең "Талфик әл-әхбәр" китабында Нургали Хәсәнов турында: "Мулла Нургали ибне Хәсән хәзерге вакытта иң күренекле галимнәрнең берсе булып тора", дип яза (2, б. 476, 486).

Ислам фәннәре белгече **Сәлахетдин ибн Сәхибзадә Әл-Әнкәби** үзенең "Бәянел Хикмәт моталәга китабына иң югары шәрех" исемле китабында Нургали хәзрәт турында "…белеме югары булган галим, бөек укытучы, Буа шәһәрендә иң камил имам – Нургали ибне шәех Хәсән", дип яза (11, б. 94).

Сембер жандармнар идарәсе башлыгы, полковник **Табельский**, Нургали Хәсәновны тикшергәннән соң, 1912 елны Сембер губернато-

ры А.С. Ключаревка язган хатында аны «мусульманский ученый старого уклада», дип бәяли[2].

1905 елда танылган православ миссионеры **С.В. Чичерина** үзенең юлъязмаларында Буа өязе хакимияте вәкилләренең ахун Нургали Хәсәновка карата ихтирамлы мөнәсәбәтен түбәндәге сүзләр белән искә ала: «Когда к чиновнику – интеллигентному русскому человеку, занимающему известное положение, приходит в шелковом халате и чалме ахун, который чувствует, что он оказывает честь русскому тем, что пришел, то русский интеллигент сажает его любезно. А если придет священник, особенно инородческий, его и не посадит, и большей частью даже руку ему не подаст» [15, с. 350].



Күренекле галим, көнчыгышны өйрәнүче, филология фәннәре докторы, профессор **Габдрахман Таһирҗанов** (1907–1983) үзенең автобиографиясендә, Нургали хәзрәт, әнисе ягыннан, абыйсы булуы турында яза. «Ул – Бохарада белем алган, ә Буада зур мәдрәсә тоткан», дип искә ала. 1920-1922 елларда булачак профессор Буа мәдрәсәсендә укый. Уку йорты ябылганнан соң галимнең өлкән улы Гаясетдин хәзрәт йортында абыйсы белән яши, анардан гыйлемнәр алалар һәм Нургали Хәсәновтан калган зур китапханәсеннән файдаланалар (12, 318 б.).



Танылган дин әһеле, тарихчы, язучы, педагог, Буа өязе Яңа Тинчәле авылы имамы **Касыйм Бикколов** (1868-1937), галим Нургали Хәсәннең Буада эшләвенә 30 ел тулуы уңаеннан, 1916 елның 5 гыйнварында «Кояш» гәзитендә болай яза:

«Буа шәһәре бер кечкенә шәһәр булса да, үзенең бөек мәдрәсәләре, олуг мөдәррисләре сәясендә аның исеме күп җирләргә мәгълүм мәшһүр булды. Мондан алтмыш еллар элек бина ителгән мондагы таш мәдрәсә муллалар бишегенә тикмәгә генә лаек иске бер бинадыр. Шунда укып чыккан талибәләр [укучылар] әгәр бер журналга язып барылса, шөбхә юк аларның саны меңләр булыр иде. Фәкать Нургали хәзрәттән генә укып чы-

[2] ГА УО ф. 885, оп. 1, д. 1137, л. 8.

ккан шәкертләрдән бүгенге вакытта 200 якын имам, бик күп мөәзин, 10 якын ахун, [дәүләт уку йортларында] берничә учитель, ике Дәүләт Думасы вәкиле [депутаты], күп мөгаллим, зур мәдрәсә тотып күп шәкертләр тәрбия итүче 7-8 мөдәррисләр бардыр. Боларны ихтибарга алганда Нургали хәзрәтнең хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәсе тәкдир ителмәслек түгелдер. Хич хаксыз, иҗрасыз, армый-талмый хезмәт итеп гүзәл нәтиҗәләр күрсәткән милләт һәм дин өчен үзенең бөтен рәхәтен калдырып, сәләмәтлеген корбан иткән мөдәррисне хөрмәт итеп, аның хезмәт милиясен [лаеклы] тәкъдир кылмак милләтебезнең, хосусан мөхтәрәм хәзрәткә шәкерт булганнарның бурычыдыр.

Дөрес хәр җирдә булганы кебек дәмулланың мәдрәсәсендә һәм үзендә кайбер кимчелекләр булсада хәрбер хезмәттә булырга мөмкин. Әмма аның бүген күренеп торган хезмәтләре инкар ителәчәк түгелдер. Без чын күңелдән дәмулланың хезмәтен тәкъдир кылабыз. Булачак юбилейга шатлык илә тәбрик итәбез!» (XXV).



Совет чорының һәм Татарстанның танылган дин эшлеклесе, казый **Габделхак Саматов** (1930–2009) үзенең «Милләтебездә Ислам дине» китабында тәсәввуф (ишанчылык) бүлегендә татар халкындагы суфичылык тарихы хакында тәфсилләп яза. Революциягә кадәр булган иң танылган ишаннары язганда болай ди: «Даны еракларга таралган абруйлы Зәйнулла ишан Троицки бик күп мөридләр тәрбияләгән. Чистайның Закир хәзрәтләр, Буада Нургали хәзрәтләр бик абруйлы булып танылганнар», – дип искә ала.

## 3.2. Галимнең бәяләнүе, бүләкләнүе

Ислам мәгарифе өлкәсендәге югары казанышлары һәм халык белән уңышлы эшчәнлеге өчен Нургали Хәсәновка төрле дәүләт бүләкләре бирелгән. 1897 елның 6 декабрендә император Николай II дән «Тырышлык өчен» көмеш, 1905 елның 1 гыйнварында алтын медаль (берсе Беренче бөтенроссия халык санын алуда ярдәм өчен), шулай ук 1906 елны 18 октяберендә мөселманнарның хәлифе, төрек солтаны Габделхәмид II дән I дәрәҗәле «Османлы» мөселман дөньясының иң югары ордены белән бүләкләнгән. Тагын бер медаленең исеме әлегә билгеле түгел (XXXII, XI, с. 48; XII, б. 29).

## 3.3. Гаилә тормышы

Нургали Хәсәнов ике тапкыр өйләнә. Беренче хатыны – Хәлимә-ай (Халиябанат) Габдрахмановадан (халык аны Бохари абыстай дип йөрткән) балалары күп туган, әмма улы Гаясетдиннән кала, барысы да вафат була. Икенче хатыны – Бибихаҗәр – Габденнасыйр хәзрәт Мөхәммәдәминовның кызы. Бу никахтан да, Ибраһим исемле улыннан башка, барлык балалары вафат була (XII, б. 26; IX, с. 389).



*Олы улы –*
*Гаясетдин Хәсәнов*



*Кече улы –*
*Ибраһим Хәсәнов*

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Нургали Хәсәновның ике хатыны да (абыстай) аңа хатын-кызлар белән эшләүдә ышанычлы ярдәмчеләр булганнар. Башка татар муллаларында кебек үк, аның да йортында мәхәлләдәге кыз балалар өчен башлангыч белем мәктәбе оештырылган була. Монда абыстайлар ел саен – көздән алып язга кадәр кыз балаларга дини сабак биргәннәр. Шулай ук атнаның һәр җомгасында ир-атлар мәчеткә барсалар, мәхәллә хатын-кызлары галимнең йортына җыелыша торган булганнар. Анда абыстайлар вәгазь сөйләгәннәр, Коръән, дини-әхлакый китаплар укыганнар, үгет-нәсихәт биргәннәр. Мондый җыелышлар еш кына чәй эчүләр белән бергә үрелеп барган. Нургали Хәсәновның хатыннары, аның ярдәмчеләре буларак, хатын-кызлар арасында «Коръән мәҗлесе», «Мәүлид уку», мәрхүмне озату, искә алу кебек дини йолаларны үткәрүдә катнашканнар. Алар

мәхәллә хатын-кызларына күп кенә гаилә һәм башка мәсьәләләр буенча киңәшчеләр булып торганнар.

Галимнең ике хатыны хатын-кызлар аудиториясендәге мөридләр белән эшләүдә ярдәмчеләр булалар, аларга зекерләр алырга һәм суфыйчылык юлында рухи камилләшергә булыштылар (XXII). Шулай итеп, революциягә кадәр татар хатын-кызларының, ир-атлардан аермалы буларак үз дөньялары булган. Абыстайлар мәхәллә хатын-кызларының дини тормышында үзәк роль уйнаганнар.

## IV БҮЛЕК. ИҖАТЫ, ӘСӘРЛӘРЕ, ҮЛЕМЕ
## 4.1. Шиһабетдин Мәрҗанигә мөнәсәбәте

Нургали Хәсәнов татар халкының мәшһүр галиме Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) белән якыннан аралашкан. Яшь аермасы зур булуга карамастан, аларны берләштергән уртак әйберләр күп булган. Икесе дә Урта Азиядә «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә зур дини гыйлем алганнар, халык арасында галим буларак танылганнар. Алар икесе дә Буа шәһәре имамы Габденнасыйр хәзрәт Мөхәмммәтәминовның кызларына өйләнгән булганнар. Нургали хәзрәт Шиһабетдин Мәрҗани белән даими күрешеп торган, барча китапларын укып барган, бигрәк тә гарәп телендә язылган китапларны искиткеч үгет-нәсихәтләре һәм матур сүзле булуы өчен мактаган. Ул аның танылган китабын «Назурат әл-хакк» («Китаб назурат аль хакк фи фардият әл-аша вә ин лям ягиб аш-шәфак» – «Караңгылык төшмәүгә карамастан, ястү намазын уку фарыз булу хаклыгына караш» (1870)) һәм аның көндәшенең «Җәрүдәнең» китабын («Музһир әл-кәлимәт әлҗарудә ал-лати хийа фи-н-назура» – «Нәзүрада булган яман сүзләрне ачыклау» (1874)) Бохара галимнәренә алып барган, галимнең фикерләрен яклап чыгышлар ясаган. Моның белән беррәттән,



*Шигабутдин Марджани*

Нургали хәзрәтнең, Шиһабетдин Мәрҗанинең кайбер фикерләрен, мәсәлән, галәмнең мәңгелек булуга карата тәнкыйди караштa булган. Ул галәмнең чикле булу икәнлеген расларга тырышкан, чөнки аны Аллаһ бар иткән, ә фәкать Аллаһ кына мәңгелек була ала, дип язган[3] (X).

Кадимчелек фикерләрен алга сөрүче Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов дин галиме «Тәүших» исемле китап язып, Ш. Мәрҗанинең «Нәзурат аль-хакк...» һәм «Хизамат аль-хаваши ли-идахат аль-гаваши» хезмәтләрен тәнкыйтьли. Нургали Хәсәнов аңа каршы җавап итеп, «Рисаләи нурия» исемле саллы хезмәтен чыгара. Ул китабында Мәрҗанинең хаклы булуын җентекләп раслый, аның хезмәтләренә төрле татар дин галимнәренең, шул исәптән Дагыстан галимнәреннән килгән уңай бәяләрне дәлил итеп китерә. Җавап итеп, Ишмөхәммәт хәзрәт аның үзен тәнкыйтьли башлый. Россиянең танылган дин галиме Зәйнулла ишан Рәсулев (1833-1917) Нургали хәзрәтне хаклы булуын яклап чыга. Бу саф гарәп телендә язылган китапларга игътибар итсәк, ул вакытларда татар җәмгыятендә дини фикернең нинди югары дәрәҗәдә булуын күзаллый алабыз[4].

Нургали хәзрәтнең Шиһабетдин Мәрҗани тууына 100 ел тулу уңаеннан ясаган чыгышы сакланып калган. Ул алар арасында булган туганлык һәм дуслык хисләре булуы турында, галимнең казанышларын югары бәяләп сөйләгән, төшләрендә ни рәвештә күрүен искә алган, аңа хәер-дога кылган (XIII, б. 463).

## 4.2. Галимнең әсәрләре

Дин галиме Нургали Хәсәнов иҗади эшчәнлеккә дә вакыт тапкан. Үз гомерендә ул егермедән артык китап яза, 1910 елга кадәр аларның унысын бастырыга да өлгерә. Тугызын без КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә, Россия Милли китапханәсендә, Фәннәр Академиясенең Көнчыгыш кулъязмалар институтында (Санкт-Петербург) һәм Нургали Хәсәновның шәхси китапханәсендә таптык. Моннан тыш ул татар вакытлы матбугатында шактый гына мәкаләләр бастыра. Хезмәтләренең күпчелеге фикъһ мәсьәләләренә, гарәп теле, суфичылык, укыту тәртипләренә карый. Китап ахырында аларның исемлеге китерелә.

[3] Эш шунда ки, Ш. Мәрҗани, Аллаһ бар нәрсәне дә барлыкка китергән һәм дөнья да аның мәхлугы, дигән гакыйдәдә торган. Шул ук вакытта, дөнья мәңгелек яки вакытлыча дигән мәсьәләгә килгәндә, ул фәлсәфи мәсъәлә дип йөрткән – Сәгыйд-Дамир Шәһәвиев искәрмәсе.

[4] Уфа шәһәрендәге Мәрьям Солтанова исемендәге мәдрәсә директоры, Башкортостан Республикасының Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары – Малахов Илдар Заһидулла улы (1968-2021) аңлатмасы.

## *Нургали Хәсәновның басылган китаплары*
























## 4.3. Галимнең үлеме

Нургали Хәсәнов гомеренең соңгы ике елында еш кына авырыса да мәдрәсәдә белем бирү эшчәнлеген туктатмый һәм җәмәгать тормышында актив катнаша. Ул еллар илдә зур үзгәрешләр, тетрәнүләр чорына туры килә: беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елда патша хакимиятенең бәреп төшерелүе һәм Вакытлы хөкүмәт урнаштырылуы, шул ук елны большевиклар властька килүе, канкойгыч гражданнар сугышы – ниһаять, Буа шәһәренең йә аклар, йә кызыллар кулына күчүе, халыкны тентүләр, талаулар һәм ачлык афәте... Бу хәлләрнең барысында да Нургали хәзрәт Хәсәнов үз йөрәге аша кичерә. Кызганыч ки, ул чор буенча тарихи чыганаклар аз сакланган. Илебез тарихының шушы фетнәле чорында Нургали Хәсәновның нинди сынаулар кичерүен күз алдына гына китерәсе кала. Каты авырудан соң, 1919 елның 19 маенда, 67-нче яшендә аның гомере өзелә.

Татарның танылган дин галимен соңгы юлга озатырга Сембер, Буа, Тәтеш өязләре авылларыннан бик күп халык җыела. Ул Буа шәһәренең татар зиратында иң хөрмәтле кешеләр янәшәсендә җирләнә. Аның изге эшләрен уллары һәм күпсанлы шәкертләре давам итә...

Нургали хәзрәт вафат булганнан соң, аның олы улы Гаясетдин (1889-1937) беренче мәхәллә мәчете имамы һәм Буа мәдрәсәсе җитәкчесе булып кала, 1923 елның 1 гыйнварында совет хөкүмәте мәдрәсәне япкач, ул гаиләсе белән Бохарага күченеп китә. Аның урынында галимнең кече улы Ибраһим (1895-1937) – 1930 елның 1 гыйнварында мәчет ябылганчы – имам, балаларга дини дәресләр бирүче булып кала. Аларның икесенең дә гомерләре 1937 елда сәяси репрессияләр һәм илдә барган дингә каршы көрәш нәтиҗәсендә өзелә.

* * *



*Габделмалик Мөлеков*

Дин галиме Нургали Хәсәновның якты истәлеге бүгенгә көнгә кадәр сакланып килә. 1996 елның мартында Буа мәдрәсәнең мәчете, иске таш уку биналары һәм аның шактый җире Габделмалик (Малик) Мөлеков (1923-2005) тырышлыгы белән мөселманнарга кайтарылып дини уку йорты яңадан ачылып китә. 1997 елның 1 октябрендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзаратының имамлар, дин белгечләре әзерли торган махсус урта профессиональ мәдрәсә буларак

үз эшчәнлеген дәвам итә. 73 ел эчендә мәдрәсә комплексы биналарының бер өлеше сакланмаган, ә аларның җирләре шәхси кулларга күчкән. 1999-2002 елларда җимерек агач мәчет урынында, мәчет, уку сыйныфлары, тулай торак, ашханә һ.б. булган Буа мәдрәсәсенең ике катлы яңа зур бинасы төзелә. Хәзер биредә көндезге, кичке, читтән торып уку, балалар һәм өлкәннәр өчен оештырылган төрле дини курсларда укытулар бара.

Уку йорты алга таба үсешен дәвам итә, яңа уку биналары төзелә, укыту эшчәнлеге киңәйтелә. Шуның белән бергә, галимнең данлыклы исеме дә, тарихта сакланып калган изге эшләре дә онытылмый.

## Йомгаклау

Билгеле булганча, Ислам дине, күп кенә халыкларның, шул исәптән татарларның тарихи язмышына, аның этно-мәдәни үзенчәлегенә зур йогынты ясаган. Күренекле татар дин галимнәре, рухи остаз-ишаннар, имам-мөәзиннәр, абыстайлар, шәһитләр, юмарт байлар, дин өчен фидакәрь хезмәт куючылар халкыбызның рухи иманын үстерүгә һәм аны иң яхшы идеалларда тәрбияләүгә бәяләп бетергесез өлеш керткәннәр. Бу шәхесләр арасында дин галиме Нургали Хәсәнов аерым урын алып тора. Бу фәнни хезмәттә без аның күпкырлы тормышы һәм эшчәнлеге хакында төп мәгълүматны җиткерергә тырыштык.

Нургали Хәсәновның тормыш юлын өйрәнгәннән соң, аның XIX гасыр азагы – XX гасыр башы Урта Идел буенда яшәгән мәшһүр дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче галим, абруйлы рухи остаз булганлыгы ачыклана. Аның бөтен гомере, яшь чагыннан ук, дин белән бәйле булган. Ул Ислам дине буенча киңкырлы гыйлем алган, рухи яктан камилләшкән һәм дини мәгариф өлкәсендә фидакарь хезмәт күрсәткән танылган шәхес булганын күрәбез. Буа һәм аннан чиктәш өязләрнең иҗтимагый тормыш үзәгендә булган Нургали Хәсәнов, шул чордагы татар дөньясының күп кенә күренекле шәхесләре белән якыннан аралашкан. Дини әсәрләр, татар газет-журналларына мәкаләләр дә язып калдырган. Аның бөтен эшчәнлеге Ислам дине, татар милләтенең, дәүләтнең үсешенә, халыкка гыйлем һәм рухи тәрбия бирүгә юнәлтелгән булган. Шул сәбәпле аның күркәм исеме татарлар тарихында озак еллар сакланып, безнең көннәргәчә килеп җиткән.

# Файдаланган чыганаклар һәм әдәбият

## Чыганаклар

**I.** Буа мәдрәсәләре // Мәктәп. – 1913. – 7 май (№ 5). – 103 б.

**II.** Ульяновск өлкәсе дәүләт архивы (УӨ ДА). Сембер губернасының Сембер округ суды фонды (Ф. 1). Оп. 22, Д. 82. к. 79; Оп. 96, Д. 59. 67 к.

**III.** УӨ ДА. Сембер губернаторы канцеляриясе фонды (Ф. 76). Оп. 2, Д. 1446, 98 л.; Оп. 7, Д. 909. 123 к.

**IV.** УӨ ДА. Сембер губернасы идарәсе фонды, Сембер шәһәре (Ф. 88). Оп. 1. д. 1930, л. 127; Оп. 4. 209, к. 275; Д. 264, 124 к.

**V.** УӨ ДА. Фонд директор – Сембер губернасы училищелары инспекторы (Ф. 99). Оп. 1. Д. 1182, к. 45, 189

**VI.** УӨ ДА. Православие динен тоту ведомствосының Сембер рухи тарихы фонды (Ф. 134). Оп. 7, Д. 839, к. 187

**VII.** УӨ ДА. Сембер губернасы жандарм идарәсе фонды (Ф. 885). Оп. 1, Д. 1137, к. 210

**VIII.** Татарстан Республикасы Милли архивы (ТР МА). Казан губернаторы канцеляриясе фонды (Ф. 1). Оп. 87, Д. 16, к.156

**IX.** ТР МА. (Ф. 204), Мәчетләрнең метрик китабы: Оп. 177. Д. 518. 462 к.

**X.** *Нургали Хәсән әл-Буави.* Рисаләи нурия. – Казань: Император ун-ты Типо-литографиясе, 1899. – 139 б. (гарәп телендә).

**XI.** *Нургали ибне шәех Хәсән әл-Казани.* Ал-гауатыф ал-хамидия фиссаяхәти нурия. – Казан: Братья Каримовы, 1907. – 80 б. (гарәп телендә).

**XII.** *Нургали ибне шәех Хәсән әл-Казани*, *әл-Мирзави*. 58 ел гасырда җәүәлән. – Оренбург: Дин вә мәгыйшәт, 1910. – 32 б. (татар телендә шигъри җыентык).

**XIII.** *Нургали Х.* Мәрҗани хакында искәрмәләрем // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 462–465.

**XIV.** *Ризаэддин Фахреддинов.* Сәяхәтнамәләр // Шура. – 1915. – № 11. – Б. 323–330.

**XV.** Әтраф хәбәрләре. Буа // Йолдыз. – 1908. – 29 июль (№ 289). – Б. 3.

**XVI.** Әтраф хәбәрләре. Буадан // Йолдыз. – 1912. – 20 март (№ 810). – Б. 3.

**XVII.** Буа өязе мөселманнары «җәмгыять хәйрия»сенең отчеты. 1910–11 нче ел өчен. – Казан, 1912. – 15 б.

**XVIII.** *Тәүфикъ Сабитов*. Буада ак чәчәк бәйрәме. Әтраф хәбәрләре. // Йолдыз. –1912. 26 апр. (№ 824). – Б. 3.

**XIX.** Буада // Кояш. – 1914. – № 541. – Б. 3.

**XX.** Ышбу ватан сугышында каһарманлык күрсәткән Георгиевский кауалыйлар үә мохтаҗ гаиләләре файдасына Ислам мәхәлләләре тарафындан җыелынмыш иганәләрнең хисабы // Мәгълүмат – 1917. – 1 гыйнвар, №1. – Б. 20.

**XXI.** Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее. – ф. 15.

**XXII.** *Зәйнәпбану*. Хатын-кыз галәме. Буа өязендә // Әл-Ислах. – 1907. – 24 июнь. – №35. – Б. 4.

**XXIII.** Чүкеч. – 1908. – 1 гыйнвар. – №37. – 3 б.

**XXIV.** *Ибрагим Мараш*. Религиозное обновление в тюркском мире (1850–1917). Перевод с тур. – Казань: Иман, 2005. – С. 154.

**XXV.** *Мулла Касыйм Бикколов*. Утыз ел хезмәт хәтирәсе // Кояш. – 1917. – 5 гыйнвар. – №1064. – С. 3.

**XXVI.** Азгыш. Мөхәбәрләремездән. Буада // Кояш. – 1914. – 13 апреля. – №386. – С. 5.

**XXVII.** Буа мәдрәсәләре һәм Бахтеев // Йолдыз. – 1915. – 17 декабря. – №1572. – С. 4.

**XXVIII.** Гаяс Хәсәни. Буадан // Казан мөһбире. – 1906. – 14 июль. – №116. – С. 3-4.

**XXIX.** Әтраф хәбәрләре. Управадан акча алу // Йолдыз. – 1912. – 4 март. - №801. – С. 3

**XXX.** Әтраф хәбәрләре. Буадан // Йолдыз. – 1916. – 22 август. – №1683. – Б. 4.

**XXXI.** Азгыш. Мөхәбирләремездән. Буадан // Кояш. – 1913. – 3 декабрь. – №277. –Б. 5.

**XXXII.** Центральный государственный исторический архив Республики Башкортостан **(**ЦГИА РБ), ф. и-259, оп. 2, д. 283, л. 3;

**XXXIII.** Дахили хәбәрләр // Казан мөхбире. – 1906. – №57 (29 март). – Б. 3

## Әдәбият

1. *Фәхреддин Р.* Асар / Төзүчеләр: Л. Байбулатова, Р. Йөзмөхәммәтов, А. Салахов, Р. Миңнуллин, И. Гыймадиев, С. Хафизова. – Казан: Рухият, 2010. – Т. 3–4. – 648 б.

2. *Рәмзи М.* Талфик аль-ахбар ва талких аль-асар фи вакаи Казан ва Булгар ва аль-мулук ат-татар [«Казан, Болгар һәм татар патшалары

турында хәбәрләр һәм ядкарьләр җыентыгы»]: 2 томда. – Оренбург: Тип. Каримова и Хусаинова, 1908. – Т. 2. – 540 б. (гарәп телендә).

3. *Баруди Г.* Хәтирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017. – 236 б.

4. *Акмулла.* Шигырьләр / Төзүчесе М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 271 б.

5. *Салихов Р.*, *Хәйретдинов Р.* Татарстан Республикасы Буа районы торак пунктлары тарихыннан. – Казан: ТР ФА Тарих ин-ты, 2002. – 108 б.

6. Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Мусульманская община г. Буинска и Буинского уезда на рубеже XIX – начала XX в. // Мечети в духовной культуре татарского народа (XVII в. – 1917 г.). Материалы Всероссийской научно-практической конференции (25 апреля 2006 г., г. Казань). – Казань, 2006. – 240–252 с.

7. *Саматов Г.Г.* Милләтебездә Ислам дине. – Казан: Иман, 1998. – 189 б.

8. *Кобзев А.В.* Исламская община Симбирской губернии во второй половине XIX – начале XX вв. – Н. Новгород: Медина, 2007. – 446 б.

9. *Маликов И.М.* Исмәгыйль нәселе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2019. – 24 б.

10. *Маликов Р.И.* Буа мәдрәсәсе тарихы. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2015. – 40 б.

11. *Сәлахетдин бине Сахибзадә әл-Әнкәби.* «Бәянел Хикмәт моталәга» китабына иң югары шәрех. – Казан: Вечиславов Типографиясе, 1892. – 94 б.

12. *Таһирҗанова А.Н.* Муса әфәнде, аның чоры һәм замандашлары турында китап. – Казан: Идел-Пресс, 2010 – 576 б.

13. *Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда / Габдулла Тукай. – Академик басма, 4 том: проза, публицистика (1907-1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 485 б.

14. Буа ягым – тау ягым. Буинские просторы. – Казан: Идел-Пресс, 2000. – 448 с.

15. *Чичерина С.В.* У приволжских инородцев: путевые заметки. – СПб.: Тип. В. Я. Мильштейна, 1905. – 427 с.

16. *Ибрагим Мараш.* Религиозное обновление в тюркском мире (1850–1917). Перевод с тур. – Казань: Иман, 2005. – 199 с.

17. *Каюмов Р.Х.* Әхмәр бине Юныс әл-Толымбаи. – Казан, 2020. – 80 б.

18. *Ömer Hakan Özalp.* Nurali bin Hasan. Sultan Abdülhamid'in Sarayında. Bir Tatar Müderrisin Istanbul, Bursa ve Surre Alayı ile Hac

Hatıraları [Во Дворце Султана Абдулхамида. Память о паломничестве татарского мудерриса в Стамбуле, Бурсе и Сурре]. – Istanbul: ISARET YAYINLARI, 2001. – 486 s.

19. *Бәшири З.Ш.* Сайланма әсәрләр: истәлекләр, бәян, публицистик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 488 б.

# КУШЫМТА

## Галимнең басылган әсәрләре һәм кулязмалары

***Кулъязмалар:***

1. *Нургали ибне Хәсән әл-Буави.* Рисаләи нурия [Нурлы әсәр], 1899 ел. // КФУ Н.И. Лобачевский ис. Фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 3095 ар. – 70 к. (гарәп телендә).

2. *Нургали ибне Хәсән әл-Буави.* Миссионер Доронкинны кире кагу, 1902 гел // Россия Фәннәр академиясе Көнчыгыш белеме институтының Кулъязмалар һәм документлар бүлеге, (РФА ИВР ОРД)). Рук. В 2584.

***Басылган әсәрләр:***

1. *Нургали Хәсән әл-Буави.* Рисаляи нурия [Нурлы әсәр]. – Казан: Император университетының типо-литографиясе, 1899. – 139 б. (гарәп телендә).

2. *Нургали Хәсән әл-Мирзави.* Рухания китабы. Ундүрт баб үзрә [Рухи дөнья турында китап. Ундүрт бүлектән тора]. – Казан: Бәянел хак, 1908 ел. // Россия милли китапханәсе. 2-8787 / татар. – 16 б. (татар телендә).

3. *Нургали ибне шәех Хәсән әл-Казани.* Әл-гауатыф әл-хәмидия фиссаяхәти нурия. [Якты сәяхәтнең игелекле хисләре].– Казан: Братья Каримовы, 1907. – 80 б. (сәяхәтләре турында, гарәп телендә).

4. *Дамелла Нургали хәзрәт* Йуз кавагид фикхия уа йуз кавагид осулия-далила уа масаилалары айла [Ислам хокукларының йөз нигезләмәсе һәм Дәлилләр һәм мисаллар белән Ислам хокукларының йөз нигезләмәсе]. – Казан: Братья Каримовы, 1902. – 35 б. (гарәп телендә).

5. *Дамелла Нургали хәзрәт.* Китаб джамигуль фунун әл-гарабият [гарәп фәннәре җыентыгы]. – Казан: Братья Каримовы, 1902. – 32 б. (гарәп һәм татар телендә, дәреслек).

6. *Дамелла Нургали хәзрәт.* Китаб аль-магарифу гайнуль якыйн уа маталубу хаккаль якыйн [Ышанычны күзләр белән аңлау һәм чын ышаныч темалары] (Мөхәммәдшәриф Әхмәтҗан улы Бакиров хираҗәте илә бастырылган). – Казан: Императ. ун-ты тип., 1901. – 36 б. (гарәп һәм татар телендә).

7. *Ахун вә мөдәррис Нургали ибне шәйх Хәсән әл-Казани, әл-Мирзави*. 58 ел гасырда җәүәлән [Бер йөзьеллыкта 58 ел сәяхәт]. – Оренбург: Дин вә мәгыйшәт, 1910. – 32 б. (татар телендә шигъри җыентык).

8. *Нургали ибне Хәсән әл-Буави*. Гажаеб мухиммат кавагид хикмият санат ва шахур камарият санат ва шухур шамсият башларны ва баситат кабисат [Кабисә елында карарлар чыгару мәсьәләләрендә искиткеч мөһим кагыйдәләр, кояш һәм ай календарьларын чагыштыру…]. – Казан, [1900] (татар телендә).

9. *Нургали Хәсән*. Китабел-хидаятер-раббания фи асрарел-шаригател-исламия. Ахкам шаригиянең хикмат газыйматлареда дыр [Изге дин турында илаһи бүләк. Шәригать кануннарын зурлау хикмәте]. – Казан, 1901 (татар телендә).

10. *Нургали Буави*. Китабел-ануарел-галия фил асрарел-кодсия [Изге серләрдә бөек нур]. – Казан, 1896 (гарәп телендә).

***Татар газета-журналларында әлеге вакытка табылган 5 мәкаләсе:***

**1.** *Ахун вә мөдәррис Нургали ибне Хәсән*. Буа шәһәрендә Нургали хәзрәтнең мәдрәсә программасы // Дин вә мәгыйшәт. – 1913. – 27 сент. (№ 38). – 606–607 б.

**2.** *Буа шәһәреннән ахун вә мөдәррис Нургали ибне Хәсән әл Мирзалари*. Телефонла шәһадәт хакында // Дин вә мәгыйшәт. – 1910. – 20 авг. (№ 34). – 538–540 б.

**3.** *Буа шәһәреннән ахун вә мөдәррис Нургали бин Хәсән углы*. Өч мәсьәлә хакында // Дин вә мәгыйшәт. – 1908. – 15 авг. (№ 32). – 493–495 б.

**4.** Буада мәдрәсә Нурия идарәсеннән мәгълүмат // Йолдыз. – 1916. – 22 авг. (№ 1683). – 4 б.

**5.** *Буа шәһәреннән ахун вә мөдәррис Нургали бин Хәсән әл-Мирзалари.* 53 номер маглүматта дәриҗ улынмыш телефон хөкемнәре хакында // Мәгълүмат. – 1910. – 1 авг. (№ 56). – 1467–1469 б.

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш................................................................................... 4**
**I Бүлек. Уку, белем туплау чоры ........................................ 5**
1.1. Балачак һәм уку еллары.............................................................5
1.2. Бохарада укуы..............................................................................7
**II Бүлек. Буа төбәгендәге эшчәнлеге ................................10**
2.1. Мәчет һәм мәдрәсә җитәкчесе ...............................................10
2.2. Иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге ..................................................17
2.3. Хаҗ сәфәре ......................................................................................23
**III Бүлек. Нургали Хәсәнов хакында.....................................24**
3.1. Галим хакында күренекле шәхесләрнең әйткән сүзләре ....24
3.2. Галимнең бәяләнүе, бүләкләнүе..............................................27
3.3. Гаилә тормышы............................................................................28
**IV Бүлек. Иҗаты, әсәрләре, үлеме.........................................29**
4.1. Шиһабетдин Мәрҗанигә мөнәсәбәте ....................................29
4.2. Галимнең әсәрләре......................................................................31
4.3. Галимнең үлеме.............................................................................31
**Йомгаклау ..................................................................................33**
**Файдаланган чыганаклар һәм әдәбият ...............................34**
**Кушымта. Галимнең басылган әсәрләре**
**һәм кулязмалары ......................................................................37**

*Нургали Хәсәновның медальләре*






*Османлы империясе (Төркия) солтаны Габделхәмид II биргән I дәрәҗәдәге «Османлы» ордены*

*Россия империясе патшасы Николай II тарафыннан бирелгән «Тырышлык өчен» медале*




*Дин галиме Нургали Хәсәновның кабере. Буа шәһәре, 2020 ел*




**Амишов Рәшид Ильяз улы**
тарихчы, педагог, фәнни хезмәткәр


1986 елның 1 декаберендә Норлат шәһәрендә дөньяга килә. Бала һәм яшүсмер чагы Буада үтә. 2003 елны Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге татар гимназиясен, 2004 елны Буа мәдрәсәсен, 2008 елны Татар дәүләт гуманитар-педагогик университетының (ТДГПУ) тарих факультетын, 2011 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты аспирантурасын, 2015 елны Россия ислам универсететының шәригать факультетын тәмамлый. «XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы Казан губернасындагы мөселман дин әһелләренең социаль торышы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 2019-2022 елларда Казан федераль университетының доктарантурасында укуын дәвам итә һәм «XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башындагы Россия империясенең Идел-Кама буендагы мөселман дин әһелләренең көндәлек тормышы» дигән темага тарих фәненнән докторлык диссертациясен яза.

Хезмәт юлын 2010 елны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы дини эшләр идарәсендә башлап җибәрә. 2011 елдан Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти ярдәмчесе, 2012-2017 елларда Буа мәдрәсәсе директоры, 2012-2018 елларда шунда ук мәдрәсәдә һәм 2018-2019 елларда Социаль белем академиясенең Буа филиандa өлкән укытучы, 2013-2019 елларда Буа районының Әлки төп гомуми белем бирү мәктәбендә педагогик эшчәнлек алып бара, 2018 елдан Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институтының ислам мәгарифен һәм ислам динен өйрәнүне үстерү ресурс үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, 2021 елдан Россия кооперациясе университетының Казан кооператив институты филиалында гуманитар фәннәр һәм чит телләр кафедрасы доценты булып эшли.

19 гасыр ахры – 20 гасыр башы татарлар арасындагы Ислам дине тарихы һәм Буа шәһәре тарихы буенча 8 китап һәм 100гә якын фәнни мәкаләләр авторы.


vk.com/rashid.amishov

**rashidbua@mail.ru**